**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Мәсгүт авыл җирлеге Яхшы-Бай торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**24 ноябрь 2022 ел.** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле узидарә оештырунын гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131 номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы 35 статьясы нигезендә 2023 елның 24 ноябрендә түбәндәге сорау буенча узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре буенча гаражданнар җыенының йомгаклау протоколы төзелде: Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәсгүт авыл җирлеге Яхшы-Бай торак пунктында 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында белем алучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән карата 500 сум күләмендә, мобилизация буенча чакырылган гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларына, 2 төркем инвалидлар өчен 250 сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсъәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тотуга ризамы:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр өчен күперләрне һәм юлүткәргечләрне, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау өчен;

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмәгә яраклы рәвештә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә 51 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 40 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

гражданнар җыенында катнашкан 40 кеше “РИЗА” позициясе өчен тавыш бирде; "КАРШЫ" позициясе өчен җыенда 0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар кабул итте:

1. Азнакай муниципаль районы Мәсгүт авыл жирлеге Яхшы-Бай торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыенынын нәтиҗәләре – гамәлдә дөрес дип таныга.

2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул ителгән дип таныга:

Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәсгүт авыл җирлеге Яхшы-Бай торак пунктында 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында белем алучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән карата 500 сум күләмендә, мобилизация буенча чакырылган гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларына, 2 төркем инвалидлар өчен 250 сум күләмендә үзара салым кертү һәм

җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсъәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тотуга ризамы:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юллары составына керми торган җәяүлеләр өчен күперләрне һәм юлүткәргечләрне, җәяүлеләр өчен җир өсте кичүләрен ремонтлау өчен;

Әлеге карарны, кабул ителгәннән соң 10 көн дәвамында, Мәсгүт авыл җирлегенең Яхшы-Бай торак пунктының мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән игълан итәргә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәсгүт авыл жирлеге башлыгына жибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Мәсгүт авыл җирлеге башлыгы:






Д.З. Миңнеханов